РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ЮЛБАТСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422077, Республика Татарстан, Сабинский район, с. Юлбат, ул. Г.Тукая, 57
тел. (84362) 43-7-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮЛБАТ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422077, Татарстан Республикасы, Саба районы, Юлбат авылы, Г.Тукай урамы, 57 йорт
тел. (84362) 43-7-22

e-mail: Ulbat.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
27.07.2026

КАРАР
№ 29

Саба муниципаль районы Юлбат авыл башкарма комитетының 17.12.2024 №43 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Юлбат авыл башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» 17.12.2024 №43 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– таблицада түбәндәге юлларны төшереп калдырырга:

«

| | | |
|---|---|---|
| 370 | 1 08 07175 01 1000 110 | Авыл җирлеге җирле үзидарә органы тарафыннан куркыныч, авыр йөк һәм (яки) зур габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы автомобиль юллары буенча хәрәкәт итүгә махсус рөхсәт биргән өчен, җирлек бюджетларына күчерелә торган дәүләт пошлинасы |
| 370 | 1 08 07175 01 4000 110 | Авыл җирлеге җирле үзидарә органы тарафыннан куркыныч, авыр йөк һәм (яки) зур габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы автомобиль юллары буенча хәрәкәт итүгә махсус рөхсәт биргән өчен, җирлек бюджетларына күчерелә торган дәүләт пошлинасы |

».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ulbat адресы буенча рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Юлбат авыл җирлеге Башлыгы Т.Р. Шәмсиев